КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 29 март г.Казань № 187

«БАСУ» автоном коммерциягә карамаган оешмасын төзү турында

«Коммерциягә карамаган оешмалар турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасында физик культура һәм спортны үстерү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының «БАСУ» автоном коммерциягә карамаган оешмасын (алга таба – Автоном оешма) төзү турындагы тәкъдимен кабул итәргә.

2. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына:

Автоном оешманы гамәлгә куючының функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашырырга;

30 көн эчендә Автоном оешма уставын расларга;

Автоном оешманы дәүләт теркәвенә алуны законнар белән билгеләнгән тәртиптә тәэмин итәргә;

30 көн эчендә Автоном оешманың күзәтү советы составы буенча тәкъдимнәрне Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертергә;

Автоном оешма төзүгә бәйле башка чараларны үткәрергә.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин